**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«23» 04 2021 ел Яр Чаллы № 1220

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының муниципаль ихтыяҗлары өчен товарлар кайтару, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булган контрактларга банк хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру очракларын билгеләү турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясы 2 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контрактларга банк хезмәте күрсәтү турында» 2014 елның 20 сентябрендәге 963 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының муниципаль ихтыяҗлары өчен товарлар кайтару, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булган контрактларга банк хезмәте күрсәтү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контрактларга банк хезмәте күрсәтү турында» 2014 елның 20 сентябрендәге 963 номерлы карары нигезендә расланган Контрактларга банк хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру кагыйдәләре нигезендә түбәндәге очракларда башкарыла:

1.1. контрактны үтәү кысаларында банк тарафыннан хисап мониторингын үткәрүдә төзелә торган контрактка банк хезмәте күрәсәтүгә карата, әгәр контрактның башлангыч (максималь) бәясе, бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән төзелә торган контракт бәясе 50 млн. сумнан да ким булмаса;

1.2. хезмәт күрсәтелгән контрактны үтәү кысаларында банк тарафыннан хисап мониторингын үткәрүгә өстәмә рәвештә, кабул ителә торган товарларның, эшләрнең (аларның нәтиҗәләренең), хезмәт күрсәтүләрнең контракт шартларына туры килүен тәэмин итәргә мөмкинлек бирүче башка хезмәтләр күрсәтүне (киңәйтелгән банк ярдәме) күздә тоткан контрактка банк хезмәте күрәсәтүгә карата, әгәр контрактның башлангыч (максималь) бәясе, бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән төзелә торган контракт бәясе 500 млн. сумнан да ким булмаса.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин